ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» октябрь 2021 ел № 333

«Әгерҗе муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгы турында нигезләмәне раслау һәм хәрби вакытта һәм Әгерҗе муниципаль районы территориясендә оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе составын раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 05 мартындагы 82 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Әгерҗе муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгы турында нигезләмәне раслау һәм хәрби вакытта һәм Әгерҗе муниципаль районы территориясендә оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе составын раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 05 мартындагы 82 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацы «Әгерҗе муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе составы» үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**